وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№14 (183). 5 апрель 2013 / 24-җөмәдиәләүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ ▷2◁




"РОССИЯДӘ, БАР ДӨНЬЯДАГЫ КЕБЕК ҮК, БЕРДӘМ "ХӘЛӘЛ" СТАНДАРТЫ ЮК" ▷2,4◁



МӨФТИЯТТӘ ГАИЛӘ, ХАТЫН-КЫЗЛАР ҺӘМ БАЛАЛАР ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА КОМИТЕТ ТӨЗЕЛӘ ▷3◁

# "МОХТӘСАР КУДУРИ" – ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕНЕҢ ТИРӘН НИГЕЗЛЕ КИТАБЫ

**Ислам динендәге төрле мәзһәбләргә кагылышлы мәсьәләләр турындагы белем (фикъһе) буенча беренче фундаменталь хезмәтләр һиҗри ел исәбе буенча II гасыр башларында - III гасыр ахырларында күренә башлый. Мондый китапларда төрле мисаллар тикшерелгән һәм алар сорау-җавап рәвешендә төзелгән. Хәнәфи мәзһәбендә бу төр китапларга без имам Мөхәммәднең "Әл Асыл" хезмәтен кертеп карый алабыз; әлеге иҗат җимешендә Әбу Хәнифәнең, Әбу Йосыфның һәм авторның үз фикерләре чагылыш таба. Мәлики мәзһәбендәгеләр өчен моңа охшаш китап булып "Мүдәүвәнә" торса, шәфигыйлар исә "Үмм" хезмәтенә таяна.**




Аннан соң бүлекләргә һәм темаларга берләштерелгән фундаменталь текстлар (мәтен) барлыкка килә башлый, алар нигездә мәзһәб имамы фикерләреннән, ә кайбер очракта әлеге мәзһәбкә караган соңгы дәвер галим фикерләреннән төзелгән. Мондый китаплар, ятларга теләгән кешеләр өчен җиңел булсын өчен, күләме ягыннан зур булмаган. Озакламый әлеге китапларга күптөрле аңлатмалар (шәрех) язылган.

VIII гасырдан соң яшәгән хәнәфи мәзһәбе галимнәре аеруча дүрт хезмәтне билгеләп узалар (алар аны "мүтүн әл арбага" дип атаганнар). Болар - "Мухтәр", "Кәнз", "Викая", "Мәҗмәгуль Бәхрәйн". Шуннан соңгы галимнәр өч китапка басым ясаганнар (алар тарафыннан ул "мүтүн ас сәләсә" дип йөртелгән): "Викая", "Кәнз", "Мохтәсар Кудури" [Кара: Габделхәй Ләкнәви. Әл Фәвәидү әл Бәһия фи тәраҗимил хәнәфия. - Б. 106-107].

Күргәнебезчә, хәнәфи мәзһәбе галимнәре һәрвакыт әлеге биш фундаменталь текстка таянган ("Кудури", "Мухтәр", "Кәнз", "Викая", "Мәҗмәгуль Бәхрәйн").

Миннән хәнәфи мәзһәбенә караган китаплар турында язуымны сораган күп кенә мөселман кардәшләребезнең үтенече буенча, Аллаһның ярдәме белән, алда санап үтелгән биш китап арасында иң беренче булып дөнья күргәне - "Мохтәсар әл Кудури" турында әйтеп узарга телим.

**"Мохтәсар әл Кудури"**. Әлеге хезмәтнең авторы - **Әхмәд ибн Мөхәммәд Әбелхөсәен әл Кудури (428/1037)**, китап 12 мең сорау-теманы үз эченә ала [Кара: Кәтиб Чәләби. Кәшф аз Зунүн. Т. 2. - Б. 1631]. Башка классик хезмәтләр кебек үк, ул да темаларга (мәсәлән, намаз турында, ураза турында һ. б.) һәм бүлекләргә бүленгән. Әлеге китап чистарыну (тәһарәт) бүлегеннән башлана һәм мираска хокук (фәраиз) бүлеге белән тәмамлана.

Бу хезмәт нинди дә булса мәсьәлә буенча дәлилләр эзләүгә йөз тотмый һәм анда башка мәзһәб фикерләре дә кителми, үзәк урында Әбу Хәнифә карашлары тора, аннан соң имам Әбу Йосыф һәм Мөхәммәд әш-Шәйбәни (Әбу Хәнифәнең ике укучысы) фикерләре бирелә.

Әгәр дә кечкенә генә тикшерү үткәреп, әлеге хезмәтне язганда имам Кудури нинди китапларга таянганын ачыкларга тырышсак, без аның Әбуҗәгъфәр әт-Тәхавиның (321/933) "Мохтәсар" китабына берникадәр мөрәҗәгать иткәнлеге турында искә алуларны таба алабыз. Шулай ук аның Әбелхәсән әл-Кархыйның (340/951) "Мохтәсар" хезмәтен файдалануы да бик мөмкин, чөнки имам Кудури әлеге китапка аңлатма (шәрех) язган; сүз башы буларак ул аның шәкерте Әбугали әш-Шаши (344/955) сүзләрен китерә: "Әлеге китапны ятлаган кеше безнең мәзһәб буенча баручылардан булса, моны аңлап укучылар әлеге мәзһәбкә ныклап төшенүчеләрдән саналадыр". Кудури китабындагы темаларның бирелү тәртибе, эчтәлек ягыннан бай булуы, аның хәнәфиләрдә өстәл китабына әверелеп китүенә сәбәп була (бу урында "Мохтәсар Кудури"ның башка күп кенә китаплар өчен чыганак булып хезмәт иткәнен дә әйтеп узарга кирәк). Мәсәлән, "Түхфәтүл Фүкахә" китабының авторы Галәветдин әс-Сәмәрканди (539/1144), Кудурида телгә алынмаган мәсьәләләрне тикшерү һәм авыр аңлашыла торган урыннарга ачыклык кертү максаты белән, шул исемдәге китабын язарга карар кыла.

Борһанетдин Маргинани (593/1197) имам Мөхәммәд әш-Шәйбәнинең "Җәмигъ әс Сагыйр" һәм "Мохтәсар Кудури" китапларына таянып, үзенең күпләргә мәгълүм "Һидәя" (аның мәтене "Бидәя әл Мөбтәди") китабын яза. Шулай ук Мәхмүд ибн Әхмәднең (673/1274) "Викая" китабы "Һидәя"нең кыскартылган мәтене (төп тексты) булып тора, димәк, аның чыганаклары арасында "Мохтәсар Кудури" китабы да бар.

**"Мәҗмәгуль Бәхрәйн".** Бу китапның авторы Ибн әс Сәгатаи (693/1294) үзенең кереш сүзендә файдаланылган чыганаклар турында искә алып, аны язганда "Мохтәсар Кудури"га һәм "Мәнзумәтүн Нәсәфия"гә (аның авторы Әбухафс Гомәр ибн Мөхәммәд ән-Нәсәфи (537/1132)) таянганлыгы турында әйтә. Китапта төрле мәзһәбләргә нигез салучыларның (аерым алганда, имам Мәлик һәм имам Шәфигый) фикер аерымлыклары турында сүз бара.

Барыбызга да аңлашылганча, "Мохтәсар Кудури" китабы хәнәфи мәзһәбенең шуннан соңгы барлык китапларына да зур йогынты ясый һәм аны хаклы рәвештә Әбу Хәнифә мәзһәбенең тирән нигезле (фундаменталь) китабы дип атарга мөмкин.

"Мохтәсар Кудури" бик күп тапкырлар бастырып чыгарылган, аңа берничә дистәдән артык аңлатма язылган, әйтергә кирәк, шуның иң беренчесе Кудуриның Акта (474/1081) исемле укучысы тарафыннан эшләнгән. Әлегә бу аңлатма нәшер ителмәгән (ул кулъязма рәвештә генә йөри); миндә булган мәгълүматлар буенча, аны басмага әзерләп яталар. Әлеге китапка иң киң таралган аңлатма булып "Әл Лүбәб фи шәрхил китәб" тора (аның авторы Габделгани әл Гунәйми (1298/1881) хәтта Ибн әл Габидиннең укучысы булган).

Киләсе мәкаләләрдә, иншә Аллаһ, хәнәфи мәзһәбенә кагылышлы бүтән фундаменталь хезмәтләр турында да сүз алып барырга тырышырбыз. "Мохтәсар Кудури" буенча минем дәресләремне www.darulfikr.ru сайтында тыңлый аласыз.

**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе/мөфти вазыйфаларын башкаручы**

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӨФТИ УРЫНБАСАРЫ ЧИСТАЙДА УЗГАН ЧАРАЛАРДА КАТНАШТЫ

**Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллинның урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов Чистай шәһәрендә үткән чараларда катнашты.**

Хәзрәт Чистайның Әнәс мәчетендә танылган татар ишаны Мөхәммәдзакир Камалов-Чистави истәлегенә багышланган укуларны үткәрүгә әзерлек утырышында булды. Җыелышны Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин алып барды.

Илдар хәзрәт Әнәс мәчете призына үткәрелгән армрестлинг буенча Бөтенроссия турниры ярышларын да карады.

### БӨГЕЛМӘДӘГЕ САБЫЙЛАРГА ХӘЙРИЯ ЯРДӘМЕ КҮРСӘТЕЛДЕ

**1 апрель көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова һәм бүлек хезмәткәрләре Бөгелмә районы үзәк хастаханәсендә булды.** Белгәнебезчә, ата-аналары ташлаган сабыйларга ярдәм итү максатыннан, Татарстан мөфтияте "Болгар" радиосы һәм Бөгелмә мөхтәсибәте белән бер ай дәвамында "Сабыйга" акциясе уздырды. Чара барышында хастаханәдә вакытлыча тәрбияләнүче, ата-аналары ташлаган сабыйларга беренчел кирәк-яраклар җыелды.

Бүлек хезмәткәрләрен Бөгелмә районы имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, баш табиб Башкирова Елена Геннадьевна каршы алды. Диния нәзарәте вәкилләре хастаханәгә хәйрия ярдәме йөзеннән электр плитәсе һәм микроволновка, акция кысаларында җыелган бала кирәк-яракларын тапшырды, аннары сабыйлар янында булды.

### ИНГУШЕТИЯ БАШЛЫГЫ КАЗАННЫҢ СӨЛӘЙМАН МӘЧЕТЕНДӘ БУЛДЫ

**3 апрель көнне Ингушетия башлыгы Юныс бәк Евкуров Казанның Сөләйман мәчетендә булды, анда ул Россиядәге бердәнбер Сукыр мөселманнар өчен тернәкләндерү үзәге эшчәнлеге белән танышты.**

Юныс бәк Евкуров мәчеттә булганда тернәкләндерү үзәгендә белем алучылар белән аралашты (алар арасында Ингушетия һәм Чечня мөселманнары да бар). Әңгәмә вакытында ул монда барган эшкә соклануын җиткерде һәм, тормыш шартларына кармастан, монда укырга килүче сукырларның батырлыгын билгеләп үтте.

### КАҺВӘ КОМПАНИЯСЕ "ХӘЛӘЛ" ТАНЫКЛЫГЫ АЛДЫ

"Вокруг Света" каһвә компаниясе чыгара торган "Цикорий растворимый" продуктына "Хәләл" таныклыгы бирелде. Әлеге компания Мәскәү өлкәсендәге Наро-Фоминский районында урнашкан. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты "Здоровье" сәүдә маркалы "Цикорий растворимый" продуктына биргән таныклык 2013 елның 29 мартыннан 2014 елның 28 мартына кадәр гамәлдә булачак.

*Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан алынды*

# ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

**Кукмара мөселман мәдрәсәсе өчен март ае төрле чараларга бай булды. Ай башында мәдрәсә мөдире Чаллыдагы Ак мәчетнең 20 еллыгына багышланган "Социаль процесслар тотрыклануда исламның роле" дип исемләнгән фәнни-гамәли конференциядә катнашкан булса, 12 мартта мәдрәсәнең II һәм IV курс шәкертләре Нәзир һәм Райнур Рәхимҗановлар Россия ислам институтында үткән "Татарларның дини-рухи мирасы" дип аталган конференциядә докладлар белән чыгыш ясады.**

17 март көнне Кукмара мәдрәсәсендә инде күркәм гадәткә әверелгән "Мөслимәләр бәйгесе" үткәрелде. Анда бездә белем алучы гүзәл затларыбыз үзара ярышты. Бәйгедә 4 төркем - кичке бүлекнең III-IV һәм башлангыч бүлекнең III курс талибәләре "көч сынашты". Алар төрле номинацияләр буенча осталыкларын күрсәтте: үзләре белән үзенчәлекле итеп таныштыру, Коръән уку, вәгазь сөйләү, мөселманча кием үрнәкләрен күрсәтү, җиләк-җимешләрдән матур композицияләр ясау һ. б. Шәкерт кызлар һәм ханымнар шулай ук мәдрәсәдә өйрәнелә торган фән программалары буенча төзелгән викторина сорауларына да җавап бирде. Мөслимәләрнең осталыгын мөгаллимәләрдән торган абруйлы жюри бәяләде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, ул көнне мәдрәсәгә "Татарстан - Яңа гасыр" телевидениесе вәкилләре - "Нәсыйхәт" тапшыруы хезмәткәрләре дә килеп, бәйге күренешләрен, дәресләр барышын төшереп китте. Әлеге сюжет 29 март (җомга) көнне эфирга чыккан "Нәсыйхәт"тә күрсәтелде (аны "ТНВ" сайтында "Нәсыйхәт" тапшырулары бүлегендә карарга мөмкин).

22 мартта исә мәдрәсәгә зур кунаклар - Татар эшмәкәрләре корылтаенда катнашучы делегатлар килде. Районыбыз хакимияте хезмәткәрләре җитәкләгән шактый зур делегация мәдрәсә бинасын карады, уку йорты эшчәнлеге турында мәгълүмат алды. Мәдрәсә эшенә уңай бәя биреп, кунаклар, тәэсирләнеп, мөгаллимнәргә уңышлар теләде, дин-гыйлем юлында дәвамлы һәм нәтиҗәле хезмәт итүләрен теләп китте.

Ә инде ай ахырында - 30 мартта - мәдрәсәдә елдагыча намаз һәм Коръән укучылар бәйгесе булып узды. Әлеге бәйге бик тә күркәм бәйрәм төсе алды. Анда 101 бала (52 малай һәм 49 кыз), 56 олы кеше (25 ир һәм 31 хатын-кыз) катнашты. Иң кечкенә катнашучыга - 2, ә иң олысына 84 яшь иде. Конкурста катнашкан һәр балага тәм-томнардан торган күчтәнәч, олыларга - кечкенә бүләкләр бирелде, призлы урын алучылар исә кыйммәтрәк бүләкләргә ия булды.

Конкурс шартларына килгәндә, алар шундый иде: 7 яшьлек һәм аннан кечкенәрәк балалар үзләре сайлап алган сүрәләрне яки догаларны укып күрсәтергә тиеш, ә 8 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк катнашучылардан 2 рәкәгать намаз укып күрсәтү соралды. Тыңлаучы мөгаллимнәр һәр катнашучының Коръән сүрәләрен һәм догаларны дөрес, матур итеп укый белүенә, намаз хәрәкәтләрен ничек башкаруына игътибар итеп, иң яхшыларын ачыклады. Катнашучылар яшьләре буенча түбәндәге төркемнәргә бүленде: 7 яшьлек һәм аннан кечерәк сабыйлар; 8-12 яшьлек балалар; 13-17 яшьлек яшүсмерләр; 18 яшьлек һәм аннан өлкәнрәкләр. Коръәннең ахыргы 22 сүрәсен яттан белүчеләр аерым төркемнәрдә ярышты.

Бәйге үткән көнне мәдрәсәнең өч каты да гөрләп торды. Кечкенәрәк балаларның әтиәниләрен яки әби-бабаларын да исәпкә алганда, бәйрәмдә ике йөздән артык мөселманның булуы мәгълүм. "Бердәмлектә - көч, хәрәкәттә - бәрәкәт" диләр безнең өлкәннәр. Кукмара мәдрәсәсендә уздырыла торган чаралар да, халыкның күпләп динебезне өйрәнәбез дип белем алып йөрүләре дә шушы мәгънәле гыйбарәнең тормыштагы ачык мисалы булып тора. Дини белем үзләштерүчеләр, динебезгә багышланган бәйгеләрдә катнашучылар рух-калебләрен пакьләндерә, ислам динен ныгытуга үзләреннән өлеш кертә. Шушы изге-игелекле гамәлләребез дәвамлы булсын, мәчет-мәдрәсәләр гөрләп торсын, Аллаһ Раббыбыз мөэмин-мөселманнарны ярдәменнән ташламасын.

*Рәсемдә: "Мөслимәләр бәйгесе"ннән күренеш.*

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе директоры**



*Марат НИЗАМОВ:*

# "Россиядә, бар дөньядагы кебек үк, бердәм "Хәләл" стандарты юк"

**Әлхәмделилләһ, өммәтебез әкренләп үсә, зурая бара. Шуңа да хәләл продукция һәм хезмәт күрсәтүләргә булган сорау көннән-көн арта. Ихтыяҗ булгач, димәк, тәкъдим дә булачак. Ләкин кайвакыт тәкъдим ителгән ул продукциянең сыйфаты бик шикле була. Кибеттә ниндидер азык-төлек алган вакытта ничек итеп алданмаска соң? Әйе, шунысы хак: бу җитештерүченең һәм аны сатучының иманы никадәр нык булуына бәйле. Әгәр дә аның иманы нык икән, ул, әлбәттә, алдашмаячак, чөнки ахирәттә моның өчен аны нинди җәзалар көткәнен ул яхшы аңлый. Табыш артыннан куып, хәләл продукция белән хәзер мөселман булмаган кешеләр дә сәүдә итә башлады. Бу очракта нишләргә? Илебездә бердәм "Хәләл" стандарты эшләнгәнме? Нинди оешмалар бу даирәне карап, көйләп торырга хокуклы?**



***Безнең Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Марат хәзрәт Низамов белән булган әңгәмәбез шул сорауларга җавап эзләүдән башланды.***

- Россиядә бүгенге көнгә, бар дөньядагы кебек үк, бердәм "Хәләл" стандарты юк. Безнең илдә хәләл продукция җитештерү һәм сату ирекле сертификация буенча алып барыла. Хәзерге вакытта илебездә техник регуляция һәм метрологиянең Федераль агентлыгында (Роскомстандартта) теркәлгән биш "Хәләл" системасы бар. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәләл стандарты комитеты "Тест-Татарстан" РСМУ ЯАҖ ("Тест-Татарстан" республика сертификация методик үзәге ябык акционерлык җәмгыяте) белән берлектә 2009 елда ислам кануннарына туры килгән продукцияне ирекле сертификацияләүнең "Хәләл" ("Халяль", Halal) системасын эшләп чыгарды һәм аны техник регуляция һәм метрологиянең Федераль агентлыгында (Роскомстандарт) теркәде. Бу системага РОСС RU.К587.04ИХ01 номеры бирелгән.

Исламда барысының да нигезенә рөхсәт ителү (тыелмаган булу) принцибы салынган, ягъни ачыктан-ачык тыелмаганнардан тыш, барысы да рөхсәт ителгән. Болар шәригать нормаларының төп чыганаклары булган Коръән белән Сөннәткә салынган. Катлаулырак моментлары фәтвәләр белән җайга салына.

Шуны билгеләп китү мөһим: гадәттән тыш зарурлык кайбер азык-төлекләргә булган тыюны вакытлыча алып ташларга мөмкин. Мәсәлән, кеше критик хәлгә юлыккан, ул чүлдә берүзе торып калган һәм аның хәләл азык-төлек белән тукланырга мөмкинлеге юк, ди. Бу очракта аңа хәрам белән тукланырга була, тик ул аны туйганчы ашарга тиеш түгел, ә бәлки үзенең тормышын саклап калу һәм ачтан үлми калу максатларында гына.

Җитештерүчеләргә шәригать тарафыннан хәрам категориясенә кертелгән азык-төлек һәм башка товарларны бүлеп бирергә, сатарга, сатып алырга һәм кулланырга ярамый. Ул гына да түгел, мөселманнарга бизнесында андый товарлар әйләнеше булган ширкәтләр белән хезмәттәшлек итү һәм аларда эшләү дә тыела. Изге Коръәндә: "Аллаһ сәүдәне рөхсәт итте, ә рибаны хәрам кылды", - диелә. Мөселманнарга тыелган товарлар белән бизнес алып бару рөхсәт ителми. Бу тыюлар шәригать буенча тыелган кайбер товар һәм хезмәт күрсәтүләргә, ә атап әйткәндә, дуңгыз ите һәм составында дуңгыз ите булган азык-төлекләргә; шәригать кануннары буенча чалынмаган йорт хайваннары итенә; алкогольле эчемлекләргә; тәмәке әйберләренә һәм наркотикларга; проституция һәм порнографик продукциягә - дингә, җәмгыятькә, аның аерым әгъзаларына зыян сала торган бар

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ДОГА МОТИВЫ

**Шагыйрьнең тормышы һәм иҗатының илаһият кануннары белән тыгыз үрелгәнлеге, бу бергәлекнең иҗтимагый-тарихи шартлар, мәдәни багланышлар белән бәйлелеге турында инде шактый күп язылды. Әмма Тукайның җан халәте, Ходайның кодрәтенең чикләнмәгәнлеген кабул итүе, Аңа ышануы шагыйрь иҗатын күңел нечкәлеге белән сугарылган яңа бер алым - Аллаһтан сорау-ялвару, изге теләк - дога рәвешендә формалашкан әсәрләр белән баетуга өлеш керткән.**



Дога - "теләк", "теләү", "ялынып сорау", "үтенү" дигәнне аңлата. Дога кылучының тәне һәм калебе саф була. Шунлыктан аның күңелендәге иң яшерен теләкләренә, иң нечкә хисләренә дә ачылырга мөмкинлек туа. Ислам динендә Аллаһ белән бәндә арасында арадашчы юк. Бәндәнең кылган гамәлләрен Аллаһ Үзе күреп тора, шуңа күрә кеше дә үзен һәрвакыт Аллаһ каршында дип хис итә, теләкләрен дә Аңа үзе җиткерә. Хисле, нечкә күңелле, саф җанлы, эчкерсез, шул ук вакытта бик туры гамәлле дә булган Тукай, билгеле, үзенең һәр эшен Аллаһ хөкеменә тапшыра. Күңелендә туган ризасызлык, үкенечләрен дә, җаны гарешкә омтылырлык канәгатьлек кичергәндә дә ул Аллаһка мөрәҗәгать итә. Шунлыктан аның шигъриятендә дога жанры шагыйрьнең идея-эстетик карашларын, лирик хисләрен укучыга җиткерүнең бер алымы булып тора. Дога кылучының күңел сафлыгы, үзен Аллаһ белән икәүдән-икәү генә дип хис итүе, аңа күңелендәге иң тирән, иң садә, иң яшертен серләрен ачарга ярдәм итә. Мондый әсәрләр шагыйрьнең җан авазын укучыга җиткерергә булыша. Бу - Тукай иҗатында төрлечә гәүдәләнеш ала. Беренчедән, аның рус халкының бөек шагыйрьләре - Пушкин белән Лермонтовка бөтен гомере буена хөрмәт белән каравы, иҗатларын үрнәк итеп алып, аларның әсәрләренә иярүләр язуы белән аңлатыла. Үз чиратында А.С. Пушкин һәм М.Ю. Лермонтовның да мөселман мәдәнияте йогынтысын кичерүләре, Коръән белән рухланып иҗат итүләре мәгълүм. 1824 елда А.С. Пушкинның "Коръәнгә иярүләр"е ("Подражания Корану") циклы басылып чыга. Үзенең остазы итеп күргән, аның истәлегенә шигырьләр багышлаган, әсәрләрен тәрҗемә иткән Тукай да Пушкинның әлеге шигъри бәйләме белән таныш булган, әлбәттә. Ә шулай да рус әдәбиятындагы дини мотивларга бәйләнешле әсәрләргә мөрәҗәгать иткәндә аның күңеле М.Ю. Лермонтов әсәрләренә тартыла. Мәсәлән, "Тәәссер" әсәре. Тукай үзе бу шигырен "Лермонтовның "Молитва" сәрләүхәле шигыренә тәкълид (иярү)" дип күрсәтә. Димәк, дога мотивын ул бөек рус шагыйреннән, аңа иярү аша кабул итә. Әмма Тукай монда да эчке сизгерлек, рухи тоемлау белән үзенчә эшкәртә, мөселманлаштыра дияргә була. Ике шигырьне янәшә куйганда бу бик ачык сизелә:

*Гомеремнең иң читен, җайсыз, уңайсыз*
*бер минутында,*
*Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,*
*Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәиб*
*сүрә Коръәннән, -*
*Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.*

*В минуту жизни трудную теснится ль в сердце грусть:*
*Одну молитву чудную твержу я наизусть.*
*Есть сила благодатная в созвучье слов живых,*
*И дышит непонятная святая прелесть в них.*

*Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин елый башлыйм:*
*Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.*

*С души как бремя скатится, сомненье далеко -*
*И верится, и плачется, и так легко, легко…*

Тукай әле моның белән генә чикләнми:

*Бөтенләй сафлана күңелем; укыйм иман,*
*булам мөэмин;*
*Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин.*
*Ходайа! Син тыйган эшләр тәмам*
*әкътагъ вә әбтәр, дим;*
*Иям баш сәҗдәгә: "Аллаһы хак! Аллаһы әкбәр!" -*
*дим,*

- дип, "дога" йоласының барлык таләпләрен дә сурәтләп (Коръәннән сүрә уку, күңелеңне сафландырып, барлык дөнья гаменнән аерылып сәҗдәгә баш ию), шигырьне изге дога сүзләре белән тәмамлый.

"Ана догасы" әсәрендә шулай ук теләк теләүченең тулы дога йоласын башкаруы сурәтләнгән. Шигырьдәге "ястүеннән соңра" дигән гыйбарә дога йоласының бөтен шартлары үтәлүенә ишарә булып тора. Димәк, теләк теләүче пакьләнеп, Коръән аятьләрен укып, тәсбих тартып башта Аллаһны олылый (намаз укый), аннан соң Аңа үзенең теләкләрен ирештерә - газиз улына бәхет сорый:

*Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык*
*Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңелен арчып;*
*Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз углын:*
*"Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз улым!"*

Шунда ук шагыйрь: "Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?" - дип, карчыкка теләктәшлеген дә белдереп куя.

Тулы дога тексты белән без шулай ук Г.Тукайның туганнарына, якыннарына язган хатларда очрашабыз. Мәсәлән, 1902 елда һәм 1903 елның 30 июнендә Уральскидан өчилегә апасы Саҗидәгә язган хатыннан өзекләр: "…Алла риза булсын, гомерегез озын булып, байлыгыгыз һәм бәхетегез көннән-көн артып торсын" яки "Хәзер дә атам-анама һаман Коръән укып торам, Мәүлам кабул итсен… Хәерле гомерләреңезне теләп язгучы талибел-гыйлем Габдулла". 26 апрельдә (1904 ел) туганнары Абдулловларга язган хаты тагын да үзенчәлеклерәк. Бу хат тексты эченә ул ахун Мотыйгулла хәзрәт һәм Сибгатулла хәзрәт мәхдүмнәрнең укыган дога текстын урнаштырган: "…Сезләрнең хәзер җибәргән ун рубляне күрсәткән идем, бу рәвешчә кычкырып сезләргә хәердога кылдылар: "Ярабби илаһи, ушбу ятим шәкертнең хәленә мәрхәмәт кыйлып, акча җибәргән Гурьев байларның күңелләрен һәрвакыт шат кыйл вә ул җумартларның дошманнарын мәкъһур әйләп, йөзләрен түбән капла, вә һәм ул байлар солтаны Абдулловларны бөтен җир йөзенә мәшһүр вә данлыклы кыйл, вә янә һәртөрле бәла вә казалардан үзең сакла вә җирләрне җәннәт кыйл. Ярабби яүме кыяматтә кояш сөңге озынлыгы якын килеп, халыкның миләрен кайнатып, бәгырьләрен көйдердектә, бу җумартларны гарше күләгәсендә күләгәләндер!"

Хатлар турында сүз кузгалуга шуны әйтәсе килә: аларда әдип күңелендәге иң саф, садә, ихлас, шул ук вакытта ачынулы хисләр чагылыш тапкан. Шунда ук аларда Аллаһ исеме белән башлау, Аллаһка мөрәҗәгать, теләк, Коръән аятьләреннән булган өзекләрнең шактый күп булуы Тукаебызның ислам диненә булган ихласлылыгының тагын бер дәлиле булып тора.

**Диләрия АБДУЛЛИНА,**
***филология фәннәре кандидаты,***
***Татарстан Фәннәр академиясенең***
***Г.Ибраһимов исемендәге***
***Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының***
***әйдәп баручы фәнни хезмәткәре***

***(Дәвамы киләсе санда.)***

# Мөфтияттә Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар эшләре буенча комитет төзелә

**3 апрель көнне Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин республикабыз мөслимәләре белән очрашты. Очрашу "Хатын-кызлар дөньяны бизи" дип аталган "түгәрәк өстәл" утырышы рәвешендә барды.**

Әлеге чарада Камил хәзрәтнең ярдәмчеләре Рөстәм хәзрәт Батыров, Нияз хәзрәт Сабиров һәм Илдар хәзрәт Баязитов, Россия һәм Татарстан Мөслимәләре берлеге рәисе Наилә Җиһаншина катнашты. Очрашуга Татарстандагы хатын-кызлар оешмалары җитәкчеләре һәм активистлары, дини уку йортлары мөгаллимәләре чакырылган иде. Мөслимәләр үзләрен кызыксындырган сорауларны бирде һәм тәкъдимнәр белән чыкты. Очрашу изге Коръәннән сүрәләр уку белән башланып китте.

Камил хәзрәт очрашу вакытында элеккеге чорларда хатын-кызлар арасында да зур галимнәр булуын билгеләп үтеп, бердәмлек кирәклеген, бердәмлек булмаса берни эшләп булмаганлыгын белдерде. Аларга бергәләшеп эшләү мөмкинлеге тудырылуын җиткерде.

Бу максаттан, мөфтияттә Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар эшләре буенча комитет төзү турында игълан ителде. Биредә "Гаилә мәсьәләләре", "Балалар проблемалары", "Халыкара элемтәләр бүлеге", "Хатын-кызлар проблемалары" дигән бүлекләр эшләячәк дип көтелә. Татарстан Мөслимәләр берлегенең урыннардагы җитәкчеләре әлеге комитетның әгъзалары булып торачак.

Гомумән алганда, очрашуда мөслимәләргә, бала тәрбияләүгә һәм гаиләләр белән эшләүгә, гаилә эчендә килеп туган мәсьәләләргә кагылышлы проблемаларны хәл итү турында сүз алып барылды.

Очрашуда шулай ук Коръән тәфсирләре чыгару, сүрәләрнең иңү сәбәпләрен дә күрсәтүдә зарурлык барлыгы әйтелде. Алга таба бу мәсьәләләр Эксперт советы карамагында булачак.

Залдагы мөслимәләргә мөрәҗәгать итеп, Наилә Җиһаншина: "Аллаһтан куркып эшлик, шунда гына гамәлләребез хәерле, кирәкле һәм файдалы булыр", - дип билгеләп үтте. Ул мөслимәләр белән урыннарга чыгып эшләү, интернет аша матбугат очрашулары уздыру мөмкинлекләре барлыгын хәбәр итте. "Безнең өчен иң мөһим нәрсә - дуслык. Бер-беребезгә игътибарлы булсак иде. Җаныгыздан килә торган нур белән кешеләрне җылытыгыз", - диде Наилә ханым.

Сөйләшүдән аңлашылганча, яшь аналарны балалар өчен җәйге лагерьлар оештыру проблемалары да борчый. Аерым алганда, мондый лагерьларны күп кеше йөри торган итеп оештыру, балаларга һәм аналарга аралашырга мөмкинлек тудыру, аларның белемнәрен күтәрү мәсьәләләре көн үзәгендә тора. Билгеле булганча, Казан мөслимәләре җитәкчесе, элек табиб булып эшләгән Фәния ханым Җәләлиева үз акчасына кызлар өчен берничә ел дәвамында Кукмара районында җәйге лагерь оештырып килә. "Түгәрәк өстәл"дә бу тәҗрибәне бөтен республикага тарату зарурлыгы билгеләп үтелде.



Очрашуда шулай ук исерткеч эчемлекләр кулланучы гаиләләр белән дә эшләүнең мөһимлеге билгеләп үтелде. Дәүләт тарафыннан иҗтимагый оешмаларга бирелә торган грантларда катнашу, аны проблемаларны мөмкин булган кадәр хәл итеп була торган проектларга бирү турында да сөйләшенде. "Безгә исеме түгел, җисеме мөһим", - дип белдерде Наилә Җиһаншина.

"Түгәрәк өстәл" утырышы нәтиҗәләре буенча резолюция кабул ителде. Анда фикер төрлелегенә таянган демократик җәмгыятьтә, яшьләрне әхлаксызлыкка этәрә торган барлык чараларны да тыю мөмкин булмавын танып, бүгенге көндә югары әхлак нормаларын пропагандалау чараларын арттыру өстенлекле юнәлеш буларак билгеләп үтелә.

**Римма ГАТИНА,**
**www.tat.tatar-inform.ru**

## *Марат НИЗАМОВ:*

# "Россиядә, бар дөньядагы кебек үк, бердәм "Хәләл" стандарты юк"

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

әйберләргә дә кагыла.

***- Базарда кемнән генә сорама, барысы да итләренең хәләл булуы турында әйтә. Аларның бу сүзләренә ышанып бетәргә буламы соң?***

- Дөрес, бу бик актуаль сорау. Сез, кулланучы буларак, тәкъдим ителә торган азык-төлекнең сыйфатын тикшерергә тиешсез. Ә сатучы исә, үз товарының сыйфатын дәлилләргә тиеш. Ә ул аны ничек дәлилли ала? Сатучының әйткән сүзләре генә дәлилләү булып тормый әле. Сатыла торган товарга тиешле документлар - аны раслый торган сертификат һәм "Хәләл" таныкламалары, әгәр дә инде аерым бер шәхси кеше сату итә икән, товарның хәләл икәнлеген раслап, җирле имам кул куйган белешмәсе булырга тиеш. "Хәләл" таныкламасын һичшиксез сорарга кирәк.

***- Базарда "Хәләл" таныкламасын сорау мөмкин эшме соң?***

- Кулланучының моңа тулы хокукы бар. Ә мөселманнар исә, гомумән, ул таныклама булуын сорарга бурычлы. Ышанам: күп очракта сатучыларның андый документлары юк. Комитет хәзер хәләл продукцияне контрольдә тотуның бөтенләй башка системасын кертү өстендә эшли, бу система малны чалганнан алып сатканга кадәрге чылбырны күзәтүдә тотарга тиеш.

Быелның февралендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе вазыйфаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллинның һәр мөхтәсибәттә хәләл бүлекләре оештыру турындагы карары чыкты, ә без бу юнәлештә эшне ничек оештыру тиешлеге турында документлар пакеты әзерләдек.

Хәзерге вакытта без имамнар өчен хәләл курслары оештыру белән шөгыльләнәбез. Бу курслар имамнарны хәләл сферасының хәзерге торышы һәм "Хәләл" системасында безнең эш принциплары белән таныштыру өчен зарур.

Хәләл системасындагы контрольне астагы баскычлардан - авыллардан, посёлоклардан ук башлап оештыру турында ниятебез бар. Бу эшкә без җирле имамнарны җәлеп итәбез. Аларга нинди җаваплылык салынуны яхшы аңлыйбыз, алар да "нинди тәртә астына кереп җигелүләрен" яхшы аңлыйлар дигән өметтәбез. Республиканың бар районнарында да имамнарның җаваплы вәкилләре булачак, вазгыятьне алар контрольдә тотачак. Безнең башка юлыбыз юк.

Әгәр дә малны авылда чалганнар икән, аның хәләллеге турындагы документны җирле имам бирергә тиеш.

Хәләл азык-төлекне дөрес итеп җитештерү генә түгел, ә аны дөрес, хәләл итеп сату да мөһим. "Хәләл" кибетләре, кафе-рестораннарда хезмәт күрсәтүчеләр хәләл азык-төлекне әзерләү һәм сату үзенчәлекләрен белергә, пөхтә итеп киенгән, чиста (махсус) киемнәрдә булырга тиеш. Кулланучылар өчен намаз укырга һәм тәһарәт алырга мөмкинлек тудырылган булырга тиеш. Сатып алучылар белән мөгамәлә иткән вакытта, хезмәт күрсәтүчеләр ислам этикасы нормалар үтәргә тиеш.

Товарлар ассортиментында хәрам яки шикле категориясенә караган азык-төлек булмаска тиеш. Хәләл азык-төлекне кисү, турау өчен кулланыла торган пычак һәм кисү такталары башка азык-төлекне эшкәртү өчен кулланылырга тиеш түгел һәм дә киресенчә, башка азык-төлекне кисү, турау өчен кулланылган пычаклар белән хәләл азык-төлекне кисәргә, турарга ярамый. Хәләл азык-төлек өчен тәгаенләнгән үлчәүләр һәм кисү такталарына "Хәләл" маркасы сугылып, башка азык-төлекләр өчен тәгаенләнгән пычак һәм кисү такталарыннан аерым урында сакланырга тиеш. Хәләл азык-төлекләр башка азык-төлекләргә тияргә тиеш түгел. Сәүдә залларындагы бер үк витринада хәләл азык-төлек белән башка азык-төлекнең бергә торуына юл куелмаска тиеш.

Безнең комитетның штаты зур түгел, бар кибетләрдә дә куелган таләпләрнең үтәлешен күзәтүдә тотарга безнең мөмкинлегебез юк. Мин хәләл продукция белән сәүдә итүче кибет һәм базарларны үзләренең күзәтүе астына алырга дип, хәләл продукция кулланучылардан ярдәм сорар идем. Кулланучының үзеннән дә яхшырак контролёр була алмый. Ул коррупциягә, чит йогынтыга бирелми. Шулай дип әйтү дөрес булса, без астан контроль - "кулланучы тикшерүе" урнаштырырга ниятлибез. Әгәр дә без шулай бергә эшләсәк, хәләл азык-төлек сатучылар да алга таба тартылырлар һәм хәләл продукция сату да артыр иде. Шулай бергәләп эшләсәк, уңай нәтиҗәләргә ирешербез, иншә Аллаһ!

***- Хәләл таныкламасы алу күпмегә төшә?***

- Һәрберсе дә катгый индивидуаль. Бу эшмәкәрнең нинди хезмәт һәм аны күпме күрсәтүенә, аның күпме сәүдә ноктасы булуына һ. б. бәйле. Сертификатның бәясе шул факторлардан тора.

Мин хәзер моңа ныграк игътибар юнәлтер идем. Күпләр түбәндәгечә уйлый: менә




"Хәләл" комитеты бар, шуңа килеп гариза язасың, түлисең дә, сертификат һәм таныклама аласың. Аңлагыз, без продукциянең шәригать таләпләренә туры килүен генә тикшереп калмыйбыз, ә лабораторияләрдә товарның сыйфатын, хәвефсезлеген ачыклыйбыз һәм аннан соң гына туры килү сертификаты тапшырабыз. "Хәләл" комитеты шәригать таләпләренә туры килүе буенча таныклама бирә, ә "Тест-Татарстан" ЯАҖ исә, товарның пробаларын алып, аның сыйфатын ачыклый. Без, үз чиратыбызда, малның шәригать кануннары буенча чалынган булуын раслыйбыз. Безнең уңай карарыбыздан соң, гаризаны "Тест-Татарстан" ширкәте карый башлый. Сертификат алуның минималь хакы - мең сум.

***- Марат хәзрәт, Татарстанда хәләл хезмәт күрсәтүләр дә барлыкка килде. Үзләрен мөселман шифаханәләре дип атаучы клиникалар, шулай ук Казанда мөэмин-мөселманнар өчен берничә чәчтарашханә бар. Алар да сездән таныклама алдымы?***

- Әйтелгәннәргә шуны өстәр идем, безнең хәтта махсус таләпләр үтәлә торган кунакханәбез дә бар. Мәсәлән, аның бүлмәләрендә тере зат рәсемнәре, сыннар юк, намаз келәмнәре бар, аларда кыйблага юнәлеш күрсәтелгән, тәһарәт алу өчен бар мөмкинлекләр дә тудырылган.

Аннан тыш, бер туристик ширкәт хәләл-туризм өлкәсендә эшләргә теләк белдерде. Шәригать кануннары кысаларында эшлибез дип игълан иткән бар бу оешмалар да, әлбәттә, "Хәләл" туры килү таныкламасы алсалар, яхшы булыр иде.

***- "Е-шка"лар дип аталучы азык-төлек өстәмәләре зур борчу тудыра. Кайсы Е-өстәмәнең хәләл, ә кайсының хәләл түгел икәнен ничек ачыкларга?***

- Бүгенге көндә азык-төлекләргә карата кулланылучы мең биш йөздән артык Е-өстәмә дип атала торган өстәмәләр бар. Кызганыч, аларның барысы да кеше организмы өчен бер үк дәрәҗәдә файдалы түгел. Чөнки бу өстәмәләр җитештерүчеләрнең үзләре тарафыннан эшләп чыгарыла. Бар проблема шунда: бу өстәмәләр азык-төлекнең сыйфатын яхшырту өчен генә түгел, ә аның отышлы тышкы кыяфәтен һәм озак саклану вакытын барлыкка китерү (саклау) өчен дә кулланыла. Шуңа күрә тәмне көчәйтү, төс бирү өстәмәләре, консервантлар, ароматизаторлар файдаланыла. Е-өстәмәләр кулланучы мәнфәгатьләрендә түгел, ә җитештерүче мәнфәгатьләрендә эшләнгәннәр дип әйтергә була, һәм без шулай ук кулланыла торган ингредиент һәм рецептураларны игътибар белән тикшерәбез.

Бервакыт безнең белән шундый очрак булган иде. "Хәләл" таныкламасы рәсмиләштергәндә "Бөтнек" дигән ароматизаторның составын ачыкларга кирәк иде. Җитештерүче бу өстәмә буенча мәгълүмат китерде. Анда нәрсә булырга мөмкин соң? Әкренләп кенә без бу мәгълүматны "сүтә" башладык. Мондый ароматизаторларның хәтта 16 (!) төре бар икәнлеге ачыкланды, аларның һәрберсенең үз номеры бар. Ул өстәмәләрне Россиядә дә, чит илләрдә дә чыгаралар икән. Ә аларның составы төрлечә, кайберләренең составында глицерин да бар. Без башта ароматизатор җитештерүчегә, ә аннан соң глицерин җитештерүчегә хат юллыйбыз. Глицеринның тереклек чыганаклымы, әллә үсемлек чыганаклымы икәнен ачыкларга кирәк. Безнең эшнең гадәти тәртибе шуннан гыйбарәт. Бу көндәлек эшләнә торган вак эш.

Ачык чагылыш алган төс бирүче шундый бер Е-өстәмә бар, ул - кармин - куе кызыл төс бирә һәм бөҗәкләрдән эшләнә. Димәк, хәләл булып чыкмый. Ләкин башка фикер дә бар: ул бөҗәкләр инде эшкәртелгән, шулай булгач, аларның сыйфаты үзгәргән һәм ул - хәрам түгел. Менә шундый гади булмаган вазгыять. Безнең эш процессы вакытында азык-төлекнең составын бик җитди итеп, молекуляр дәрәҗәгә кадәр тикшерергә туры килә, чөнки зур җаваплылык тоябыз һәм өммәтебезнең ышанычы безнең өчен бик тә кадерле.

Рөхсәт ителгән һәм тыелган Е-өстәмәләр исемлегенә килгәндә исә, бу очракта, Е-өстәмәләр буенча Россия белешмәләреннән файдаланырга мөмкин, аларда Россиягә кертү тыелган Е-өстәмәләрнең исемлеге китерелгән. Аннан тыш мөселманнар өчен тыелган Е-өстәмәләр турында мәгълүмат булган басмалар бар. Миңа билгеле булганча, бу турыда мобиль җайланмалар өчен эшләнгән программалар да билгеле. "Е-шкалар" дип номер керткән вакытта, ул өстәмәнең бар составы турында мәгълүмат китерә.

***- Генномодификацияләнгән азык-төлекләр хәләлме, түгелме?***

- Бу мәсьәләне әле җентекләп өйрәнергә кирәк. Табигый азык-төлек - нормаль азык-төлек. Әгәр дә инде азык-төлекнең асылына геннар тирән урнаша икән, бу шик уята. Кабатлап әйтергә туры килә: болар барысы да кулланучы мәнфәгатьләренә зыян салып, җитештерүче мәнфәгатендә эшләнәләр. Ген инженериясенең максаты - уңышны арттыру һәм азык-төлекнең озаграк (табигый саклану срокларыннан зуррак) саклануын тәэмин итү. Андый азык-төлекләрнең составы шик уята, димәк, Коръәндә әйтелгәнчә, аларны кулланмаска, шикле әйбердән ераграк торырга кирәк. Әгәр нинди дә булса азык-төлек сездә шик уята икән, безгә мөрәҗәгать итегез, сорауларыгызга җавап бирергә тырышырбыз.

- *Әңгәмәгез өчен рәхмәт.*

**Наил ФӘЙЗЕТДИНОВ**

## "Тукайның йөзьеллыгы"на рәхим итегез!

***12 апрель көнне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган флешмоб-акция узачак. Бу көнне "Печән базары" ярминкәсе һәм театральләшкән тамаша узар дип көтелә. Анда яшь буын - студентлар, мәктәп балалары ярдәме белән XX йөз башы - шагыйрь яшәгән чор атмосферасы чагылдырылачак. Чара Казан шәһәренең Париж Коммунасы урамында (үткән гасыр башында әдип яшәгән һәм иҗат иткән урында) оештырылачак.***

**Ярминкәдә сәнгать эшләнмәләре, сувенирлар, кулдан ясалган әйберләр, шәмаиллар, милли ризыклар, әдәби китаплар һәм башкалабызның төрле югары уку йортларында белем алучы студентларның кул эшләре тәкъдим ителәчәк.**

**Исегезгә төшерәбез: быел җәмәгатьчелек Г.Тукайның вафатына 100 ел тулуны билгеләп үтә. 1913 елның 15 апрелендә (20 сәгать 15 минутта) шагыйрьнең йөрәге тибүдән туктый. Аңа нибары 27 яшь була. Г.Тукай - исән чакта ук халык шагыйре буларак танылу ала. Бүгенге заман тел галимнәре аны хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы дип саный.**


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 14 (183) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35397.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 4 апрель көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**